**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2017 ел, 16 март № 144

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының халыкка социаль хезмәт күрсәтүче дәүләт оешмалары һәм дәүләт социаль яклау учреждениеләре хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2012 ел, 1 август, 653 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының халыкка социаль хезмәт күрсәтүче дәүләт оешмалары һәм дәүләт социаль яклау учреждениеләре хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының халыкка социаль хезмәт күрсәтүче дәүләт оешмалары һәм дәүләт социаль яклау учреждениеләре хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2012 ел, 1 август, 653 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2012 ел, 27 ноябрь, 1036 нчы; 2013 ел, 30 гыйнвар, 52 нче; 2013 ел, 29 июнь, 458 нче; 2014 ел, 24 гыйнвар, 36 нчы; 2014 ел, 15 февраль, 91 нче; 2014 ел, 27 июнь, 443 нче; 2014 ел, 29 июль, 553 нче; 2014 ел, 2 август, 565 нче; 2014 ел, 10 октябрь, 752 нче; 2014 ел, 22 октябрь, 775 нче; 2015 ел, 2 апрель, 209 нчы; 2015 ел, 22 июль, 536 нчы; 2015 ел, 3 ноябрь, 833 нче; 2016 ел, 26 май, 356 нчы, 2016 ел, 30 июнь, 449 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасының халыкка социаль хезмәт күрсәтүче дәүләт оешмалары һәм дәүләт социаль яклау учреждениеләре хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 бүлекнең 2.5 пунктында:

бишенче абзацта «1,000» саннарын «1,142» саннарына алмаштырырга;

алтынчы абзацта «1,166» саннарын «1,332» саннарына алмаштырырга;

җиденче абзацта «1,223» саннарын «1,397» саннарына алмаштырырга;

сигезенче абзацта «1,166» саннарын «1,332» саннарына алмаштырырга;

2.5.1 пунктчаның дүртенче абзацында «1,210» саннарын «1,362» саннарына алмаштырырга;

9 бүлекнең 9.7 пунктына түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«Гамәлгә куючы Татарстан Республикасының халыкка социаль хезмәт күрсәтүче дәүләт оешмалары һәм дәүләт социаль яклау учреждениеләре җитәкчеләренә социаль характердагы түләүләр билгеләргә мөмкин.

Татарстан Республикасының халыкка социаль хезмәт күрсәтүче дәүләт оешмалары һәм дәүләт социаль яклау учреждениеләре җитәкчеләре үзләренең урынбасарларына һәм баш хисапчыларына социаль характердагы түләүләр билгеләргә мөмкин.».

2. Әлеге карарның гамәле 2017 елның 1 мартыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә тарала дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков